Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданка А.К. Закирова шикаятенә бәйле рәвештә «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 9 февралендәге 67 номерлы карарының 1 пунктының, шулай ук әлеге карар белән расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр түләү бирү тәртибе турында нигезләмәнең 1 пунктындагы беренче абзацы, 6 пунктындагы беренче абзацы һәм 7 пунктындагы алтынчы абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2019 елның 16 апреле

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 9 февралендәге 67 номерлы карарының 1 пунктының, шулай ук әлеге карар белән расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр түләү бирү тәртибе турында нигезләмәнең 1 пунктындагы беренче абзацы,

6 пунктындагы беренче абзацы һәм 7 пунктындагы алтынчы абзацының конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданка А.К. Закирова шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Э.М. Мостафина мәгълүматын, яклар — гражданка А.К. Закирова, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының юридик бүлеге башлыгы Р.Г. Миңнеголов аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең хокукый экспертиза бүлеге баш киңәшчесе А.М. Мәсләвиев, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының вәкаләтле вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы М.Б. Сөнгатуллин, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцов, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы Ю.А. Старшая, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге башлыгы Р.Р. Шкаликов, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге прокуроры М.А. Филиппова, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге башлыгы А.Г. Бартенев

чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка А.К. Закирова «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 9 февралендәге 67 номерлы карарының 1 пункты, шулай ук әлеге карар белән расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр түләү бирү тәртибе турында нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 1 пунктындагы беренче абзацы, 6 пунктындагы беренче абзацы һәм 7 пунктындагы алтынчы абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъвалана торган карарының 1 пункты белән бер тапкыр бирелә торган түләү түбәндәгеләргә билгеләнгән:

мөрәҗәгать итү датасына кимендә өч ел Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче 25 яшькә кадәрге хатын-кызларга беренче баласы туганда 50 мең сум күләмендә;

мөрәҗәгать итү датасына кимендә өч ел Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче 29 яшькә кадәрге хатын-кызларга өченче баласы туганда 100 мең сум күләмендә.

Нигезләмәнең 1 пунктындагы беренче абзацында Нигезләмә мөрәҗәгать итү датасына кимендә өч ел Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга беренче (өченче) баласы туганда бер тапкыр түләү

(алга таба — бала туганда бер тапкыр түләү) бирү тәртибен һәм шартларын билгели дигән норма бар.

Нигезләмәнең 6 пунктындагы беренче абзацы буенча бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләүне билгеләү өчен Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән гражданнар яки алар тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләтле затлар «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең яшәү урыны буенча бүлегенә (алга таба — Үзәк бүлеге) документлар тапшыралар.

Нигезләмәнең 7 пунктындагы алтынчы абзацы әлеге пунктның беренче абзацы белән үзара бәйләнештә шуны күздә тота: Үзәк бүлеге ведомствоара мөрәҗәгатьләр нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасын кулланып, электрон формада, бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында карар кабул итү өчен кирәкле булган Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда кимендә өч ел даими яшәү фактын раслый торган мәгълүматлар ала.

Шикаятьтән һәм аңа кушып бирелгән документлардан күренгәнчә, 2014 елда гражданка А.К. Закирова гаиләсе белән Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Усад поселогында социаль ипотека шартнамәсе буенча торак урын алган, анда ул ире һәм балалары белән бергә даими яши, ләкин билгеләнгән тәртиптә теркәлмәгән.

Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, мондый теркәлүнең булмавы аңа 2018 елда өченче баласы туганда бер тапкыр бирелә торган әлеге түләүне билгеләүдән баш тарту өчен нигез булган. Шулай, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы җавабыннан күренгәнчә, аңа әлеге түләүне бирү мөмкин түгел, чөнки ул, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының дәгъва белдерелә торган нигезләмәләре таләп иткәнчә, авыл җирлеге яки шәһәр тибындагы поселок территориясендә яшәү урыны буенча теркәлмәгән.

Гражданка А.К. Закирова хокук куллану практикасындагы мондый алым аның Татарстан Республикасы Конституциясе белән гарантияләнгән социаль тәэминатка хокукын боза дип саный, чөнки теркәлү факты яки аның булмавы, аның фикеренчә, хәбәр итү характерына ия һәм гражданның тору яки яшәү урыны буенча булу фактын гына чагылдыра.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 9 февралендәге 67 номерлы карарының 1 пунктын, шулай ук әлеге карар белән расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр түләү бирү тәртибе турында нигезләмәнең 1 пунктындагы беренче абзацын, 6 пунктындагы беренче абзацын һәм 7 пунктындагы алтынчы абзацын гамәлдәге хокукый җайга салу системасындагы хокук куллану практикасында бирелә торган мәгънә буенча алар хатын-кызларның бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү алуга хокукын гамәлгә ашыруны аларның Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда кимендә өч ел даими яшәү фактын теркәү исәбе органнары тарафыннан бирелгән теркәү турындагы документлар белән генә раслау тиешлеге белән бәйләгән дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 38 (беренче һәм өченче өлешләр), 54 (беренче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше я аларга өстенлекләр билгеләү тыела; гаилә, ана булу һәм балачак дәүләт яклавында; дәүләт гаилә турында, ананың һәм баланың сәламәтлеген тәэмин итү һәм балаларны тәрбияләү турында кайгырта; һәркемгә балаларны тәрбияләү өчен

һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 9 февралендәге 67 номерлы карарының 1 пункты, шулай ук әлеге карар белән расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр түләү бирү тәртибе турында нигезләмәнең 1 пунктындагы беренче абзацы, 6 пунктындагы беренче абзацы һәм 7 пунктындагы алтынчы абзацы гамәлдәге хокукый җайга салу системасындагы хокук куллану практикасында аларга бирелә торган мәгънә буенча хатын-кызларның бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү алуга хокукын гамәлгә ашыруны аларның Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда кимендә өч ел даими яшәү фактын теркәү исәбе органнары тарафыннан бирелгән теркәү турындагы документлар белән генә раслау тиешлеге белән бәйләгән дәрәҗәдә әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләр социаль яклау өлкәсенә кагыла. Россия Федерациясе

Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» пункты) нигезендә социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы, 2 һәм 5 өлешләр).

Балалары булган гаиләләрне (шул исәптән күпбалалы гаиләләрне) социаль яклау өлкәсендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен билгеләп, федераль закон чыгаручы «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3 статьясындагы 2 пунктының 24 пунктчасы, 26.3-1 статьясындагы өченче өлеше, «Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» 2006 елның 29 декабрендәге 256-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 2 өлеше нигезләмәләре буенча Россия Федерациясе субъектларына мондый гаиләләр өчен үз бюджетлары акчалары исәбеннән федераль законнар нигезендә аларга бирелә торган ташламалар, гарантияләр һәм башка социаль чараларны тулыландыра ала торган өстәмә социаль ярдәм күрсәтү һәм социаль булышу чараларын кертү хокукын бирә.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 102 (4 пункт) һәм 103 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты социаль тәэминат өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен үткәрүдә катнаша, Татарстан Республикасы территориясендә федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үтәлешен тәэмин итә, Татарстан Республикасының бөтен территориясендә

үтәү мәҗбүри булган карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара.

Шулай итеп, федераль законнар нигезендә үзенә бирелгән һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 102 (4 пункт) һәм 103 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган хокук чыгару вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2018 елның 9 февралендәге 67 номерлы карарын кабул иткән.

3. Татарстан Республикасын социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), Татарстан Республикасы Конституциясе шуны беркетә: гаилә, ана булу һәм балачак дәүләт яклавында, дәүләт гаилә турында, ананың һәм баланың сәламәтлеген тәэмин итү һәм балаларны тәрбияләү турында кайгырта (38 статья, беренче һәм өченче өлешләр); һәркемгә балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә (54 статья, беренче өлеш). Мәгънәләре буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясе, шул исәптән аның 7, 38 (1 өлеш) һәм 39 (1 өлеш) статьялары белән билгеләнгән.

Китерелгән конституциячел нигезләмәләргә Бала хокуклары турында конвенция күрсәтмәләре туры килә (БМО Генераль Ассамблеясының 1989 елның 20 ноябрендәге карары белән хупланган), ул тормышның барлык өлкәләрендә дә балалар мәнфәгатьләре һәм яшәеше өстенлеге принцибына таянып, аны имзалаган дәүләтләргә — һәр баланың физик, акыл, рухи, әхлакый һәм социаль үсеше өчен кирәк булган тормыш дәрәҗәсенә хокукын танудан чыгып, — ата-аналар һәм бала тәрбияләүче һәм аның өчен җаваплы булган башка затларның үзләренең сәләте һәм финанс мөмкинлекләре чикләрендә моның өчен шартлар тудырырга тиешлеген исәпкә алып, балаларга иминлек өчен кирәкле булган яклауны һәм кайгыртуны тәэмин итәр өчен барлык закон һәм административ чаралар күрүне йөкли (3 статьяның 2 пункты, 27 статьяның 1 һәм 2 пунктлары).

Гаиләгә, ана булуга, ата булуга һәм балачакка, шул исәптән Россиянең

күпмилләтле халкын саклап калуның һәм үстерүнең мөһим шарты буларак балалар туу санын арттыруга (гаиләләрдә икенче һәм аннан соңгы балаларны табу хисабына) юнәлдерелгән дәүләт ярдәме, Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр билгеләгәнчә, гаилә институтына конкрет-тарихи этапта Россия Федерациясенең социаль һәм икътисади сәясәте максатларына, шулай ук дәүләтнең икътисади үсеш дәрәҗәсенә һәм финанс мөмкинлекләренә тәңгәл нәтиҗәле яклау тәэмин итә торган хокукый механизмнарның булуын күздә тота (2007 елның 22 мартындагы 4-П номерлы, 2011 елның 15 декабрендәге 28-П номерлы, 2012 елның 6 декабрендәге 31-П номерлы һ.б. карарлар).

3.1. 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясе буенча Татарстан Республикасы үсешенең төп юнәлешләреннән туучылар санының уңайлы динамикасын саклау (гаиләләргә максималь тулы дәрәҗәдә балаларга ихтыяҗны гамәлгә ашыру мөмкинлеген бирү шартларын тудыру), балалы гаиләләргә социаль ярдәм чараларының адреслылыгын арттыру булып тора.

Россия Федерациясе Конституция Судының кайбер карарларында бәян ителгән хокукый позициясе нигезендә Россия Федерациясе субъекты закон чыгаручысы, аңа социаль яклау өлкәсендә бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырып, киң дискрециягә ия һәм үз акчалары исәбеннән социаль ярдәм күрсәтүнең (булышуның) формасын, төрләрен һәм шартларын, шул исәптән адреслылык принцибын исәпкә алып һәм мохтаҗлыкны бәяләү нигезендә билгеләргә дә, шулай ук күрсәтелгән өлкәдә хокукый җайга салуны үзгәртергә дә хокуклы (2014 елның 6 февралендәге 2-П номерлы, 2018 елның 27 мартындагы 13-П номерлы карарлар).

Үзенең дискрецион вәкаләтләре кысаларында эш итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган өстәмә социаль ярдәм чарасын билгеләгән, аның максатчан билгеләнеше булып авыл җирлегендә уңай

демографик тенденцияләрне стимуллаштыру һәм ныгыту, гражданнар, шул исәптән балалары булган гаиләләр өчен авыл торак пунктларына күченүгә һәм (яки) анда яшәүгә мотивация булдыру, шулай ук аларның социаль якланганлыгы дәрәҗәсен күтәрү тора. Шуңа бәйле рәвештә 25 яшькә кадәрге хатын-кызларның беренче баласы туганда һәм 29 яшькә кадәрге хатын-кызларның өченче баласы туганда аны алу хокукын гамәлгә ашыруның мәҗбүри шартларының берсе булып Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда (алга таба шулай ук — авыл җирлегендә) кимендә өч ел даими яшәү тора (дәгъва белдерелә торган карарның 1 пункты һәм Нигезләмәнең 1 пунктындагы беренче абзацы).

Дәгъвалана торган нормаларны Россия Федерациясе Граждан кодексының 20 статьясы һәм «Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе чикләрендә күчеп йөрү ирегенә, тору һәм яшәү урынын сайлауга хокукы турында» 1993 елның 25 июнендәге 5242-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 2 һәм 3 статьялары белән беркетелгән «яшәү урыны» төшенчәсенә мөрәҗәгать итмичә куллану мөмкин түгел, аларда гражданның яшәү урыны буларак ул Россия Федерациясе законнары белән каралган нигезләрдә даими яки күпчелек рәвештә яши торган һәм яшәү урыны буенча теркәлгән торак урын билгеләнгән.

Карала торган түләү алуга дәгъва итүче гражданның шул исәптән авыл җирлегендә кимендә өч ел яшәү фактын раслый торган документлар һәм мәгълүматлар исемлеге Нигезләмәнең дәгъва белдерелә торган 6 һәм 7 пунктлары белән регламентлаштырылган. Күрсәтелгән пунктлар үз чиратында граждан үзе тапшыра торган һәм ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек каналлары аша алына торган документларны һәм мәгълүматларны төгәл аералар. Шулай, гражданның авыл җирлегендә даими яшәү фактын раслый торган мәгълүматлар Нигезләмәнең 7 пунктындагы дәгъвалана торган алтынчы абзацы нигезендә шундый хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиеш.

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон мәгънәсе буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, шулай ук шундый хезмәтләр күрсәтүдә катнаша торган алар ведомствосындагы оешмалар арасында ведомство специализациясе нигезендә үзләрендә булган документлар һәм мәгълүматлар алмашу мәсьәләләре буенча гамәлгә ашырыла (2 статьяның 9 пункты).

Гражданнарның яшәү урыны буенча теркәлүе турында мәгълүмат шул исәптән Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының 2017 елның 31 декабрендәге 984 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе гражданнарын Россия Федерациясе чикләрендә тору урыны һәм яшәү урыны буенча теркәү исәбенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының административ регламенты белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәте күрсәтә торган дәүләт органнары карамагында бар.

Шуңа күрә гражданның авыл җирлегендә даими яшәү фактын ведомствоара мөрәҗәгатьләр нигезендә бары тик аның тиешле яшәү урыны буенча теркәлүе турында мәгълүматлар гына раслый ала.

Шул ук вакытта Россия Федерациясе Конституция Суды берничә тапкыр күрсәткәнчә, гражданнарның Россия Федерациясе Конституциясенә каршы килми торган мәгънәдә теркәлүе хәбәр итү характерына ия булган һәм гражданның тору яки яшәү урыны буенча булу фактын чагылдыра торган аларны Россия Федерациясе территориясе чикләрендә исәпкә алуның федераль закон белән каралган ысулы гына булып тора; шул ук вакытта затның конкрет яшәү урыны аны компетентлы органнар тарафыннан теркәү белән бәйле булмаган төрле юридик фактлар нигезендә гомуми юрисдикция суды тарафыннан да билгеләнергә мөмкин (1995 елның 24 ноябрендәге 14-П номерлы, 1996 елның 4 апрелендәге 9-П номерлы, 1998 елның 2 февралендәге 4-П номерлы карарлар; 2008 елның 6 октябрендәге 619-О-П номерлы Билгеләмә).

Россия Федерациясе Югары Суды үзенең хокук куллану практикасында игътибарны шулай ук шуңа юнәлдергән: Россия Федерациясе Граждан кодексының 20 статьясы һәм «Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе чикләрендә күчеп йөрү ирегенә, тору һәм яшәү урынын сайлауга хокукы турында» Россия Федерациясе Законының 2 һәм 3 статьялары эчтәлегеннән теркәлүнең «яшәү урыны» төшенчәсенә туры килмәве һәм үзеннән-үзе гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен гамәлгә ашыру шарты булып тора алмавы аңлашыла (Россия Федерациясе Югары Суды Президиумы тарафыннан 2016 елның 20 декабрендә расланган Россия Федерациясе Югары Судының суд практикасына күзәтүе (№ 4, 2016)).

Моннан чыгып, гражданның авыл җирлегендә даими яшәве, бала туганда бер тапкыр түләү бирү өчен мәҗбүри шарт буларак, аның яшәү урыны буенча теркәлүе турындагы мәгълүматлар белән генә түгел, ә әлеге фактны билгели торган суд карары белән дә расланырга мөмкин. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгать итүченең дәгъвалана торган нормалар хатын-кызларның карала торган түләүне алуга хокукын гамәлгә ашыруны аларның авыл җирлегендә кимендә өч ел даими яшәү фактын теркәү исәбе органнары тарафыннан бирелгән теркәү турындагы документлар белән генә раслау тиешлеге белән бәйлиләр дигән дәлилләренә раслау тапмый, чөнки Нигезләмәнең 7 пунктындагы җиденче абзацы белән мөрәҗәгать итүчеләр үз инициативасы белән Үзәк бүлегенә әлеге пунктта күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны, димәк, авыл җирлегендә кимендә өч ел даими яшәүләре фактын раслый ала торганнарын да тапшырырга хокуклы дип каралган.

Шуның белән үзләренең хокукый табигате һәм турыдан-туры эчтәлеге буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъва белдерелә торган карарының 1 пункты, Нигезләмәнең 1 пунктындагы беренче абзацы, 6 пунктындагы беренче абзацы һәм 7 пунктындагы алтынчы абзацының үзара бәйле нормалары бала туганда бер тапкыр түләү биргәндә адреслылык

принцибын, шулай ук граждан үзе дә тапшырган һәм ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында да алынган документлар нигезендә аны билгеләү турында карарны Үзәк бүлеге тарафыннан кабул итү процедурасының бертөрлелеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән механизмны билгелиләр. Үзләренең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча карала торган нормалар гамәлдәге хокукый җайга салу системасында хатын-кызларның беренче (өченче) баласы туганда бер тапкыр бирелә торган түләү алуга хокукын гамәлгә ашыру, барыннан да элек, аларның авыл җирлегендә кимендә өч ел даими яшәве белән бәйле дип күздә тоталар, үзләреннән-үзе әлеге фактны тиешле яшәү урыны буенча теркәлү турындагы мәгълүматлар белән генә раслауны күздә тотмыйлар һәм шул фактны закон нигезендә каралган ысул белән билгеләүгә комачауламыйлар.

Мондый шартларда Татарстан Республикасы Конституция суды шундый нәтиҗәгә килә: «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 9 февралендәге 67 номерлы карарының 1 пункты, әлеге карар белән расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр түләү бирү тәртибе турында нигезләмәнең 1 пунктындагы беренче абзацы, 6 пунктындагы беренче абзацы һәм 7 пунктындагы алтынчы абзацы гражданнарның күрсәтелгән түләүне алу хокукы асылына каршы төшмиләр, аның мәгънәсе югалуга китермиләр һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 38 (беренче һәм өченче өлешләр), 54 (беренче өлеш) статьяларына каршы килмиләр.

Татарстан Республикасы Конституция суды шуны билгеләп үтәргә кирәк дип саный: карала торган мәсьәләнең спецификасына, шулай ук шул исәптән югарыда аталган түләү алуга дәгъва итүче гражданның авыл җирлегендә тиешле теркәлүсез фактта яшәвен раслый торган конкрет тормыш хәлләре үзенчәлекләрен исәпкә алу кирәклегенә күрә, хокук

кулланучы мондый гражданга әлеге фактны билгеләү өчен судка мөрәҗәгать итү хокукы булуы турында аңлатырга тиеш. Әлеге мәсьәләне бәйсезлек, гаделлек һәм объективлык башлангычларында нәкъ менә суд тәртибендә җайга салу карала торган түләүне алу хокукыннан законсыз файдалану мөмкинлеген юкка чыгара һәм авыл җирлегендә даими яшәүче, ләкин анда теркәлмәгән гражданнар өчен дә, шулай ук күрсәтелгән хокукны гамәлгә ашыруны турыдан-туры тәэмин итә торган хокук куллану органнары өчен дә конституциячел акланган булып тора. Башкасы, гражданнарга бирелгән хокукның асылына карамастан, әлеге мәсьәләне хәл итүдә формаль якын килүгә һәм, нәтиҗәдә, тигезлек, закон өстенлеге, гаделлек, гражданнарның законга һәм дәүләт гамәлләренә ышанычын саклау принципларын бозып, аның хокуксыз чикләнүенә китерә алыр иде.

3.2. Мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерә торган хокукый нигезләмәләрне Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану авыл җирлегендә даими яшәүче хатын-кызларга беренче (өченче) баласы туганда бер тапкыр түләү бирү механизмын камилләштерүгә комачауламый. Әлеге түләүне алуга дәгъва итүче гражданның авыл җирлегендә кимендә өч ел даими яшәү фактын раслау тәртибен тиешле суд карарын тапшыру мөмкинлеген күрсәтеп аныклый торган үзгәрешләр кертү дәгъва белдерелә торган нормаларны төрлечә аңлатуга, ирекле куллануга юл куймас иде һәм әлеге өлкәдәге хокукый җайга салуда ачыклык, билгелелек һәм мәгънә берлеге булуга ярдәм итәр иде.

Мондый алым Кеше хокуклары буенча Европа Судының хокукый позициясенә туры килә, ул үз карарларында билгеләгәнчә, закон Кеше хокукларын һәм төп ирекләрен яклау турындагы конвенциядә билгеләнгән барлык законнарның җитәрлек дәрәҗәдә төгәл формалаштырылуын һәм юридик ярдәм кирәк булган очракта затка аның теге яисә бу гамәлләре нинди нәтиҗәләргә бәйле була алуын күзаллау мөмкинлеген бирүне таләп итә торган стандартка туры килергә тиеш (2007 елның 24 маендагы «Игнатов (Ignatov) Россия Федерациясенә каршы» эше; 2007 елның 24 маендагы

«Владимир Соловьев (Vladimir Solovyev) Россия Федерациясенә каршы» эше буенча карарлар).

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71 һәм 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 9 февралендәге 67 номерлы карарының 1 пунктын, шулай ук әлеге карар белән расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр түләү бирү тәртибе турында нигезләмәнең 1 пунктындагы беренче абзацын, 6 пунктындагы беренче абзацын һәм 7 пунктындагы алтынчы абзацын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазифаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 82-П**

**Татарстан Республикасы Конституция суды**